**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар коллективларын һәм шәхси эшкуарларны бүләкләү системасы үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты указларына кушымта нигезендә исемлек буенча үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 12 декабрь
№ ПУ-1091

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның «12» декабрендәге
ПУ-1091 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турында» 2004 елның 27 мартындагы ПУ-290 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 мартындагы ПУ-126 номерлы һәм 2012 елның 4 июнендәге Пу-416 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның беренче абзацындагы «, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктның җиденче абзацындагы «, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 15 маендагы ПУ-174 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы һәм 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе турында Нигезләмәнең 8 пунктындагы унынчы абзацында «бүләкләү документлары һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатлары» сүзләрен «дәүләт бүләкләре белән бүләкләнү һәм башка бүләкләүләр турындагы документларны» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 22 маендагы ПУ-184 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 4 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы һәм 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге турында Нигезләмәдә:

а) 6 пунктның икенче абзацында «, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 9 пунктта:

алтынчы абзацта «, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 24 маендагы ПУ-196 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 һәм 2015 елның 10 декабрендәге ПУ-1186 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе турында Нигезләмәнең 8 пунктындагы 13 абзацындагы «һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатларын әзерләү» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентын раслау турында» 2008 елның 4 апрелендәге ПУ-162 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 7 октябрендәге ПУ-667 номерлы, 2013 елның 7 маендагы ПУ-385 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1144 номерлы, 2014 елның 14 августындагы ПУ-788 номерлы, 2015 елның 22 маендагы ПУ-473 номерлы, 2016 елның 30 гыйнварындагы ПУ-67 номерлы, 2016 елның 25 июнендәге ПУ-550 номерлы, 2016 елның 12 августындагы ПУ-685 номерлы һәм 2016 елның 20 октябрендәге ПУ-948 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентында:

а) 6.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты (алга таба шулай ук – Рәхмәт хаты),» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 6.6 пунктның өченче абзацында «, Рәхмәт хаты» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6.11 пунктның икенче абзацында «, Рәхмәт хаты» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 6.12 пунктны көчен югалткан дип танырга;

д) 6.13 пунктта «, Рәхмәт хаты» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 6.19 пунктта «, Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәт хаты» сүзләрен төшереп калдырырга.